# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2020 елның 13 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Әлмәт авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Әлмәт авылы территориясендә I нче группа инвалидлардан, ялгыз өлкән кешеләрдән, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Әлмәт авылының Ленин урамында урнашкан су коесын чистарту һәм төзекләндерү;
2) Триммерлар өчен запас частьләр сатып алу;
3) Әлмәт авылы Ленин урамындагы җәяүлеләр күперен төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу;
4) Әлмәт авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
5) Әлмәт авылында МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, өстәмә җиһазлар, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү)
6) Әлмәт авылында Ленин урамы, Тукай урамы, Яшьләр урамы, Л. Рәхмәтуллин урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (асфальт өслекләрендәге ярыкларны ясау һәм герметизацияләү өчен материаллар сатып алу);
7) Әлмәт авылында генератор сатып алу;
8) Әлмәт авылында массакүләм чаралар (өлкәннәр көне, инвалидлар көне, 9 Май, яшьләр арасында волейбол, теннис ярышлары) үткәрү өчен бүләкләр алу;
9) Әлмәт торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (ремонт өчен төзелеш материаллары һәм буяулар сатып алу).

3. Әлеге карарны Әлмәт авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Д.Ә.Газизов